Мәгърифәтле татар хатын-кызларыннан



ЗӘЙНӘП ӘХМӘРЕВА

XIX йөз ахыры — XX йөз башы татар тарихында үзенчәлекле бер чор. Бу вакытта татар тормышының бик күп өлкәләрендә үзгәрешләр була. Шулардан мәгариф өлкәсен аерып күрсәтергә кирәк. Җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр татар җәмгыяте үсешен билгеләүче яңа буын татар яшьләрен тәрбиялиләр. Бу мәктәп-мәдрәсәләрне тәмамлап чыккан шәкертләр арасында татар тарихында лаеклы урын тотучы шәхесләр бик күп. XIX йөзнең икенче яртысында башланып киткән милли уяну дәвере XX йөзгә кергәндә татар хатын-кызларына да бер этәргеч була. Алар да үзләренең аң-белемнәре, җәмгыятьтәге урыннары турында ныклабрак уйлана башлыйлар. Бу чорда хатын-кыз мәсьәләсенең иң югары ноктага куелуын шул еллардагы матбугат сәхифәләре дә раслый. Аларга багышланган махсус басмалар барлыкка килә, алар үз язмалары белән дә матбугат аша чыгыш ясау югарылыгына күтәреләләр. Бу чорда татар

хатын-кызлары арасыннан эш-гамәлләре белән тарихка кереп калырга лаеклы шәхесләр үсеп чыга. Аларның эшчәнлеген ачыклауда, өйрәнүдә һәм укучыларга тәкъдим итүдә хөрмәтле галимәләребез А. Мәхмүтова[1], Т. Биктимероваларның[2] игелекле эшләрен билгеләп үтми мөмкин түгел. Шул хезмәтләр аша Маһруй Мозаффария, Ләбибә Хөсәенова, Зөһрә Акчурина һәм башка бик күп мәшһүр хатын-кызларның исемнәре билгеле. Татар җәмгыятенә фидакар хезмәт иткән туташ һәм ханымнарның исемлеге киләчәктә, һичшиксез, тулыланачак.

XX йөз башының мәшһүр хатын-кызларыннан Зәйнәп Әхмәреваны да атау кирәк. Ул тарихчы галим Гайнетдин Әхмәрев гаиләсендә 1891 елның 19 ноябрендә, гаиләдәге икенче бала булып дөньяга килә. Аның балачагы Тәтеш шәһәрендә үтә, беренче сабакларын да ул шунда ала. 1898 елны Тәтеш шәһәренең хатын-кызлар мәктәбенә укырга керә. Бу мәктәпне ачу Ж. Мускеев һәм әтисе Г. Әхмәрев тырышлыгы белән тормышка ашкан[3]. Әхмәревләр гаиләсе 1903 елда Казанга күчеп китү сәбәпле, З. Әхмәрева укуын Казан шәһәре уку йортларында дәвам итү мөмкинлеге ала. 1904 елны ул «Мариинская женская гимназия» дип аталган хатын-кызлар гимназиясенә укырга керә. Бу уку йортын 1911 елда яхшы билгеләр белән генә тәмамлап, өй шартларында да укыту хокукына ия булган башлангыч сыйныф укытучысы белгечлеге ала[4]. Ул үзенең укытучылык эшен Зөләйха Апанаеваның дүртенче номерлы рус-татар кызлар мәктәбендә рус теле укытучысы буларак башлап җибәрә. Әлеге мәктәптә аның белән бергә шул ук вазифаларны Бибигайшә Исмәгыйль кызы Корбангалиева да башкарган. Чыганаклардан күренүенчә, татар хатын-кызлар мәктәпләренең барысында да диярлек рус телен татар туташлары һәм ханымнары өйрәткәннәр. З. Әхмәрева кебек үк, рус телен укытучылардан Мәрьям Солтан кызы Еникиева, Бибиәсма Солтан кызы Еникиева (Хәдичә Әхмәрева мәктәбе), Сәгадәт Мозаффар кызы Гобәйдуллина, Мәрьям Фәсәхетдин кызы Мөхетдинова (5 нче номерлы рус-татар кызлар мәктәбе), Суфия Шакиржан кызы Таһирова (Ләбибә Хөсәенова мәктәбенең рус телен өйрәтү сыйныфы), Галия Габдулла кызы Һадиева (Фатыйма Аитова мәктәбенең рус телен өйрәнү сыйныфы) исемнәрен атап үтәргә мөмкин[5].

XIX йөз азагыннан ук татар хатын-кызларын югары уку йортларында да күрергә була. Шундыйлардан, 1872 елда ачылган югары медицина курсларын татар хатын-кызлары арасыннан беренче булып Разия Котлыярова (Касыйм шәһәре) 1891 елда тәмамлап чыга. Беренче чорда татар хатын-кызларының югары уку йортларында белем алулары төрле сәбәпләр аркасында авырлык белән барса, соңрак күп кенә татар хатын-кызлары мондый уку йортларында укуларын дәвам итү мөмкинлеге алалар.

З. Әхмәрева да берничә ел укытучылык эше белән шөгыльләнгәннән соң, Казан шәһәрендәге хатын-кызлар өчен Югары курсларга белемен арттыру максаты белән керергә дип 1917 елда документларын тапшыра[6]. Бу уку йорты 1876 елның 3 октябренә кадәр эшләп ябылганнан соң, 1906 елның октябрендә кабаттан ачыла. Монда укыту ике бүлектә алып барылган: тарихи-иҗтимагый, тел һәм әдәбият бүлекләре. 1916 елда биредә педагогик семинар да ачыла һәм уку йорты 1920 елга кадәр эшли. Зәйнәп Әхмәрева бу уку йортының тарихи-иҗтимагый бүлеген сайлый. 1917/18 уку елында З. Әхмәревадан тыш әлеге уку йортында биш мөселман кызы белем алган. Алар

— Алимбәкова Әминә Вәлиулла кызы, Габитова Рабига Шәрәфетдин кызы, Гобәйдуллина Мәрьям Салих кызы, Дәүләткилдиева Фатыйма Сәедгаскәр кызы һәм Мөхетдинова Мәрьям Фәсәхетдин кызы. Шулар арасыннан М. Мөхетдинова шәһәр стипендиаты булган. З. Әхмәрева бу уку йортында 1917 елда укый башлый һәм аның зачет кенәгәсе алуны раслап куелган имзасы бар, ләкин ул аны тәмамлап чыкканмы, юкмы — мондый документларның әлегә табылганы юк. 1918/19 уку елына карый торган документларда аның турында бернинди дә мәгълүмат юк.

З. Әхмәреваның Югары курсларга укырга керү елы катлаулы чорга туры килә. Ул бу уку йортына документларын 1917 елның сентябрь аенда тапшыра. Октябрь аенда булган инкыйлаб вакыйгаларыннан соң ул укуын дәвам итә алдымы икән? Моннан тыш, әтисез калган Әхмәревләр гаиләсенең матди хәле дә җиңелдән булмый. (Г. Әхмәрев 1911 елда вафат). Кызганычка каршы, уңай җавап алырлык документлар табылганчы, аның бу уку йортын тәмамлап чыгуы турында тәгаен генә әйтергә кыен. Ничек кенә булса да, ул үзенең мәгариф өлкәсенә багышланган эшчәнлеген туктатмагандыр дип уйлыйбыз. З. Әхмәреваның октябрь вакыйгаларыннан соңгы язмышы әлегә ачыкланмаган.

Г. Әхмәревкә багышланган тарихи-документаль җыентыкта аның гаиләсенә караган мәгълүматларны да бирергә тырышкан идек һәм ул китапта галимнең кайбер балаларының фотосурәтләре дә урнаштырылды[7], ләкин соңгы эзләнүләр нәтиҗәсендә яңа мәгълүматлар ачыла тора һәм шулай итеп, кызы Зәйнәпнең фотосурәтен дә укучыларга тәкъдим итү мөмкинлеге туды.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Махмутова А. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). – Казань, 2006. – 254 с.
2. Биктимерова Т. Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. – Казан, 2002. – 140 б.
3. ТР МА, 160 ф., 1 тасв., 907 сакл. бер., 68 а кгз.
4. Шунда ук, 125 ф., 1 тасв., 970 сакл. бер., 118, 118 а кгз.
5. Биктимерова Т. Ә. Күрс. хез. – Б. 88.
6. ТР МА, 131 ф., 1 тасв., 111 сакл. бер., 1 кгз.
7. Гайнетдин Әхмәрев: Тарихи-документаль җыентык / Төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э. Сәлахова. – Казан, 2000. – 384 б.

Фото 250 б.: З. Әхмәрева. ТР МА, 131 ф., 3 тасв., 111 сакл. бер., 1 а кгз.

Эльмира Сәлахова,
тарих фәннәре кандидаты

РЕЗЮМЕ

В статье Э. Салаховой повествуется о знаменитой женщине начала XX в. Зайнап Ахмаровой, внесшей большой вклад в развитие женского образования в татарском обществе. Биографические сведения З. Ахмаровой публикуются впервые.